ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 1[1] статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» 2009 елның 17 июнендәге 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 5; 2012, № 6 (I өлеш); 2015, № 8 – 9; 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 50 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:
«5) Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән, муниципаль район территориясендә урнашкан индустриаль парк (сәнәгать паркы) территориясендәге инфраструктура объектларыннан файдалана торган һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы белән индустриаль парк (сәнәгать паркы) территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзегән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булып торучы салым түләүчеләр өчен.

Салым ставкасы индустриаль парк (сәнәгать паркы) территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзелгән датага индустриаль парк (сәнәгать паркы) мәйданының иң күбе 70 проценты биләнгән булу шарты үтәлгәндә бирелә һәм индустриаль парк (сәнәгать паркы) территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзелгән салым чорыннан башлап мондый килешүнең

гамәлдә булу срогы тәгәлләнә торган салым чоры башланганчы, әмма 10 салым чорыннан да күбрәк түгел, кулланыла.

Индустриаль парк (сәнәгать паркы) территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.»;

2) 1[1] статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3) Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән, муниципаль район территориясендә урнашкан индустриаль парк (сәнәгать паркы) территориясендәге инфраструктура объектларыннан файдалана торган һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы белән индустриаль парк (сәнәгать паркы) территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзегән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары булып торучы салым түләүчеләр өчен.

Салым ставкасы индустриаль парк (сәнәгать паркы) территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзелгән датага индустриаль парк (сәнәгать паркы) мәйданының иң күбе 70 проценты биләнгән булу шарты үтәлгәндә бирелә һәм индустриаль парк (сәнәгать паркы) территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзелгән салым чорыннан башлап мондый килешүнең гамәлдә булу срогы тәгәлләнә торган салым чоры башланганчы, әмма 10 салым чорыннан да күбрәк түгел, кулланыла.

Индустриаль парк (сәнәгать паркы) территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 28 апрель
№ 24-ТРЗ